| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.12.2018 Казан ш. № 10-178/кс

«Генерацияләү компаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенең «Балкыш» шифаханә-профилакторий филиалы өчен агынты суларны транспортлауга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 30.11.2016 № 10-25/кс карарында билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2019 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында.

«Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2019 елга агынты суларны транспортлауга суга озак сроклы тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай табышына төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Генерацияләү компаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенең «Балкыш» шифаханә-профилакторий филиалы өчен агынты суларны транспортлауга 2017-2019 елларга тарифлар билгеләү турында» 30.11.2016 № 10-25/кс карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 01.12.2017 № 10-50/кс карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

аталышында «Генерацияләү компаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенең» сүзләрен «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Генерацияләү компаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенең» сүзләрен «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «Генерацияләү компаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенең» сүзләрен «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «Генерацияләү компаниясе» ачык акционерлык җәмгыятенең» сүзләрен «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең» сүзләренә алмаштырырга;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис в.б. А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 30.11.2016 № 10-25/кс карарына 1 нче кушымта «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2018 № 10-178/кс карары редакциясендә)

Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Балкыш» шифаханә-профилакторий филиалы өчен агынты суларны транспортлауга 2017-2019 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Агынты суларны транспортлауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2017 ел | | 2018 ел | | 2019 ел | |
| | | 01.01.2017 башлап 30.06.2017 кадәр | 01.07.2017дән 31.12.2017 кадәр | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр |
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | | | | |
| 1 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Балкыш» шифаханә-профилакторий филиалы (тарифлар НДС исәпкә алмыйча күрсәтелде) | 10,26 | 10,69 | 10,63 | 10,63 | 10,45 | 10,45 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 30.11.2016 № 10-25/кс карарына 2 нче кушымта «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2018 № 10-178/кс карары редакциясендә)

## Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Балкыш» шифаханә-профилакторий филиалы өчен 2017-2019 елларга агынты суларны транспортлауга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрлары

| № п/п | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | «Татэнерго» акционерлык җәмгыятенең «Балкыш» шифаханә-профилакторий филиалы | | | | | | |
| 1.1.1 | Агынты суларны транспортлау | 2017 | 161,83 | 1 | – | – | 0,33 |
| | | 2018 | 166,62 | 1 | – | – | 0,33 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2019 | 172,54 | 1 | – | – | 0,33 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге